ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КРИВООЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, 9а село Кривоозерки, 423051,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленина ур. 9а,, Кәкре Күл авылы , 423051

Тел. (8-84344-4-43-45) ОГРН 1061665002519,ОКПО 94318501, ИНН/КПП 1603004871 /160301001
E-mail: *Krozer.Aks@tatar.ru* , http://*Aksubaevo.tatarstan.ru*

**№18** **30 октябрь 2025 ел**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге Башкарма комитетының «2016 — 2027 елларга Кәкре Күл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү «муниципаль программасын раслау турында 25.10.2024 ел, №13 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы « Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Аксубай муниципаль районының Кәкре Күл авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАРы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге Башкарма комитетының «2016-2027 елларга Кәкре Күл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында 25.10.2024 ел, №13 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2019 — 2028 елларга Кәкре Күл программасын раслау турында".

1.2. «2019-2028 елларга Кәкре Күл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү" муниципаль программасын кушымта редакциясендә бәян итәргә.

2.Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы рәсми сайтына (http://aksubaevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кәкре Күл авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе С. С. Елисеев

**"2019 - 2028 елларга Кәкре Күл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү" муниципаль программасы паспорты**

| | |
|---|---|
| Программа исеме | «2019 - 2028 елларга Кәкре Күл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү» муниципаль программасы (алга таба текстта - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 сентябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон; Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге территорияләренең тышкы төзекләндерү, чисталыгын һәм тәртибен үтәү кагыйдәләре |
| Программа җитәкчесе | Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге " Башкарма комитеты |
| Программа Максатлары | Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә комплексклы төзекләндерү системасын камилләштерү, тәртипне, архитектура-сәнгати бизәлешне һәм санитария халәтен саклау чараларын гамәлгә ашыру. Авыл җирлегендә яшәүчеләрнең эшчәнлеге һәм ялы өчен уңайлы шартлар тудыру. |
| Программа бурычлары | -территорияләрне карап тотуның бердәм тәртибен билгеләү;<br>-территорияләрне төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга физик һәм юридик затларны җәлеп итү һәм аларның чисталык һәм тәртип саклау өчен җаваплылыгын арттыру;<br>- территорияләрдән файдалануга, аларны саклауга һәм төзекләндерүгә контрольне көчәйтү |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | - 2019 - 2028 еллар |
| Программаның төп чаралары исемлеге | - электр тапшыру линияләрен карап тоту һәм ремонтлау;<br>- юллар төзү һәм ремонтлау;<br>- зиратларны тәртиптә тоту;<br>- территорияләрне төзекләндерү |
| Программаның төп чараларын башкаручылар | - Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы " Кәкре Күл авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты;<br>- предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләре (килешү буенча); |
| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | программаны гамәлгә ашыруга финанслауның гомуми күләме 2977,0 мең сум тәшкил итә<br>2019 елда-211,0 мең сум<br>2020 ел-184,0 мең сум<br>2021 ел-184,0 мең сум<br>2022 ел-184,0 мең сум<br>2023 ел-186,0 мең сум<br>2024 ел-304,0 мең сум<br>2025 ел-322,0 мең сум<br>2026 ел-454,0 мең сум<br>2027 ел-468,0 мең сум |

| | |
|---|---|
| | 2028 ел-480,0 мең сум<br>Искәрмә: программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, шул елга тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны уртак финанслауга республика һәм район бюджетыннан акчалар бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтелергә тиеш. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту һәм идарә итүне оештыру системасы | - программа белән гомуми җитәкчелек итүне һәм аны гамәлгә ашыру барышын контрольдә тотуны программа җитәкчесе башкара. Программа җитәкчесе ел саен Программаның чираттагы календарь елына беренчел чараларын төгәлләштерә һәм алдагы елга чаралар исемлеген проектлый.<br>Программаны гамәлгә ашыру барышын тикшереп тору Программа чараларын башкаручыларның гамәлләренә ел саен мониторинг ясау системасыннан гыйбарәт.<br>Ел саен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге башкарма комитеты Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына Программа чараларын гамәлгә ашыру барышы турында хисап тапшыра. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | - программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә халык күп була торган урыннар территорияләрен төзекләндерергә, юл өслеген ремонтларга, балалар һәм спорт мәйданчыкларын төзекләндерергә, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерергә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл-обелискны яңартырга һәм башка чаралар үткәрергә. |

## 1. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү.

Әлеге Программа торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү, санитария хәлен яхшырту һәм архитектура-сәнгати бизәү буенча чараларны гамәлгә ашыру өчен төп программа булып тора.

2025 ел дәвамында җирлектә юл өслеген ремонтлау, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм Ф.А. Горшков обелискларын ремонтлау буенча эшләр башкарылган, җәмәгать урыннары һәм балалар мәйданчыгы яңартылган, ТКО өчен мәйданчыклар эшләнгән, яшелләндерү эшләре башкарылган.

Төзекләндерү проблемаларын хәл итүгә программалы-максатчан якын килү кирәк, чөнки Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзек комплекслы төзекләндерү системасыннан башка җирлектә яшәүчеләрнең эшчәнлеге һәм ялы өчен уңайлы шартлар тәэмин итүдә нинди дә булса әһәмиятле нәтиҗәләргә ирешү мөмкин түгел. Җирлекнең тормыш-көнкүрешен тәэмин итүче һәм төзекләндерү белән шөгыльләнүче администрация һәм предприятиеләр, учреждениеләр, халык эшчәнлегенең төгәл килешенгән булуы мөһим. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү перспективаларын билгеләү акчаларны төзекләндерүнең аерым элементларын агымдагы ремонтлауга тотмыйча, куелган бурычларны хәл итүгә туплауга ирешергә мөмкинлек бирәчәк.

Программаны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына гамәлгә ашырыла.

## 2. **Программаның төп максатлары, бурычлары, гамәлгә ашыру сроклары.**

Программаның максатлары һәм бурычлары булып:
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы " Кәкре Күл авыл җирлеге" территориясендә тәртип, төзекләндерү, архитектура-сәнгати бизәлеш һәм санитария хәлен саклау чараларын гамәлгә ашыру;
- халык өчен уңайлы мохит булдыру;
- ишегалды территорияләрен төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү, торак йортларга якын килүне яхшырту;
территорияләрне карап тотуның бердәм тәртибен билгеләү;
территорияләрне төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга физик һәм юридик затларны җәлеп итү һәм аларның чисталык һәм тәртип саклау өчен җаваплылыгын арттыру;
- территорияләрдән файдалануга, аларны саклауга һәм төзекләндерүгә контрольне көчәйтү;
ишегалды, квартал эчендәге машина юлларын норматив таләпләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган дәрәҗәгә кадәр торгызу һәм транспорт-эксплуатация торышын күтәрү;

Программаны гамәлгә ашыру сроклары - 2019-2028 еллар.

## 3. **Программа чаралары системасы**

Программа чараларына түбәндәгеләр керә::
- территорияне даими рәвештә кардан чистарту;
- юлларны карап тоту һәм эксплуатацияләү;
- муниципаль берәмлек территориясен яктырту;
- зиратларны тәртиптә тоту
- программаны финанслау күләмен билгеләү һәм раслау;
-программаны гамәлгә ашыру хисабын, мәгълүмати-аналитик материалларны әзерләү;
- программаның максатын һәм бурычларын хәл итүне яктыртуга, программаны гамәлгә ашыруның барышы турындагы эшне халыкка җиткерүне оештыру.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә халыкның эше һәм ялы өчен уңайлы шартлар тудыру көтелә.

Программаның нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр буенча бәяләнә:
- муниципаль берәмлек халкын төзекләндерү эшләренә җәлеп итү проценты;
- җирлек предприятиеләрен һәм оешмаларын төзекләндерү эшләренә җәлеп итү проценты;
- җирлекне төзекләндерүне тәэмин итүче предприятиеләрнең һәм инженерлык челтәрләре хуҗалары булган предприятиеләрнең үзара хезмәттәшлек дәрәҗәсе;
- муниципаль берәмлекнең төзеклеге дәрәҗәсе (камилләштерелгән өслекле автомобиль юллары, тышкы яктырту челтәрләре, яшел үсентеләр, балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары белән тәэмин ителеш).

## 4. **Программа чараларын ресурслар белән тәэмин итү**

Программа чараларын финанслау Кәкре Күл авыл җирлегенең муниципаль бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. 2019 - 2028 елларда планлаштырылган чыгымнарның гомуми суммасы – 2977,0 мең сум.

**5. Программаны гамәлгә ашыру механизмы**

Программа чараларын гамәлгә ашыру программа паспортында күрсәтелгән төп чараларны барлык башкаручылар тарафыннан гамәлдәге законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.
Әлеге программаны гамәлгә ашыруның төп координаторы-Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы.

**6. Программа белән идарә итүне оештыру, аны гамәлгә ашыру барышын тикшереп тору**

Программа чараларын вакытында һәм сыйфатлы үтәү, аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан рациональ файдалану өчен «башкаручылар»графасында күрсәтелгән оешмалар һәм ведомстволар җаваплы.

**7. Программаның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре.**

Программа түбәндәге чараларын гамәлгә ашыра:
- 22 км юлны карап тоту һәм ремонтлау;
- җирлекнең 5 торак пунктында урамнарны яктырту;
- җирлек территориясендә булган 2 зиратны тоту;
- муниципаль берәмлек халкына үзләренең кече ватанына мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләргә, чисталык һәм тәртип сакларга өнди .

Программага кушымта

"Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең 2016 - 2027 елларга авыл җирлеге территориясен төзекләндерү " муниципаль программасының төп чаралары

| № п/п | Чаралар | Еллар буенча чараларны үтәү | | | | | | | | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019г. | 2020г. | 2021г | 2022г | 2023г | 2024г | 2025 г | 2026г. | 2027г. | 2028 г. | |
| 1 | Автомобиль юлларын һәм инженерлык корылмаларын карап тоту, торак пунктлар урамнарын кардан чистарту, мең сум. | 31,3 | 30 | 30 | 30 | 30 | 50 | 45 | 49 | 45 | 45 | Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында була һәм, тиешле елга тиешле дәрәҗәдәге бюджетлар формалаштыруны, шулай ук чараларны уртак финанслауга республика һәм район бюджетыннан акчалар бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтелергә тиеш. |
| 2 | Торак пунктларның урамнарын яктырту, мең сум. | 175,4 | 150 | 150 | 150 | 152 | 190 | 203 | 220 | 234 | 246 | |
| 3 | Күмү урыннарын оештыру һәм карап тоту, мең сум. | 2 зират 4,3 | 2 зират 4 | 2 зират 4 | 2 зират 4 | 2 зират 4 | 2 зират 4 | 2 зират 4 | 2 зират 4 | 2 зират 4 | 2 зират 4 | |
| | Тракторларны карап тоту | | | | | | 60,0 | 70,0 | 185,0 | 185,0 | 185,0 | |
| 4 | Чишмәләрне төзекләндерү, данә. | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | |
| 5 | Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, данә. | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | |
| 6 | Обелискларны төзекләндерү, данә | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | |
| | Барлыгы | 211 | 184 | 184 | 184 | 186 | 304 | 322 | 454 | 468 | 480 | |